КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 19 июль г.Казань № 511

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Пенсионерларның, ветераннарның һәм инвалидларның социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы җәмәгать оешмалары чыгымнарын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 41 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Пенсионерларның, ветераннарның һәм инвалидларның социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы җәмәгать оешмалары чыгымнарын өлешчә каплау өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2009 ел, 26 гыйнвар, 41 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 25 май, 411 нче; 2012 ел, 1 декабрь, 1052 нче; 2013 ел, 3 июль, 466 нчы; 2014 ел, 10 май, 313 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Исемендә, преамбулада һәм 1 нче пунктта тиешле килешләрдәге «чыгымнарын өлешчә каплау» сүзләрен тиешле килешләрдә «чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (кайтару)» сүзләренә алмаштырырга;

Пенсионерларның, ветераннарның һәм инвалидларның социаль әһәмияткә ия булган эшчәнлекне гамәлгә ашыручы җәмәгать оешмалары чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (кайтару) өчен Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин